ДӘРЕС ЭШКӘРТМӘСЕ

ТАТАР ТЕЛЕ

3 нче сыйныф (рус төркеме, “Сәлам” буенча)

Туган тел һәм әдәбияты укытучысы Заляева К.Р.

**Тема: “**Көндәлек режим”.
**Дәрес максаты.**
<u>Дидактик максат</u> :
вакытны әйтә, сорый; кайчан нәрсә эшләгәнеңне әйтә белү күнекмәләрен ныгыту ;
көндәлек режим турында сөйләү өчен кирәк булган лексик материалны өйрәнү.
<u>Үстерү максаты</u> :
чагыштыра, нәтиҗә ясый белү кебек фикерләү сәләтләрен үстерү.
<u>Тәрбияви максат</u>:
-әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашырга, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлый белү.
**Материал**: *Дәреслек:86 нчы бит;*
**Җиһазлау:** сәгать,презентация, карточкалар, сәгать, компьютер, проектор, экран.

**Дәрес барышы:**
**I.Мотивлаштыру- ориентлаштыру**
**1.Дәресне оештыру.**
Дәрестә уңай психологик халәт тудыру.
- *Исәнмесез! Хәерле көн! Хәлләрегез ничек?*
*Бер-берегезгә карашып, елмаеп, яхшы кәеф теләгез!*

*Укучылар , бүген көн нинди? (Бүген көн җылы, яңгыр ява, җил исә, кояшлы). Димәк ,кайсы ел фасылы?(Яз.) Әйдәгез әле ,яз турындагы җырыбызны җырлап үтик.* (*Балалар “Яз җитте” җырын җырлыйлар.)*

**II.Актуальләштерү**
1.Өй эшләрен тикшерү. 82нче бит,1нче күнегүдәге сорауларга җавап бирделәр.
**III.Уку мәсьәләсен кую.**

**1.**Укучылар бу нәрсә тавышы?(качырып куелган будильник тавышы яңгырый)

Будильник безгә нәрсә өчен кирәк?(Иртә белән вакытында тору өчен)

Укучылар минем кулымда нәрсә?

- Сәгать.

- Сәгать безгә ни өчен кирәк?

- Вакытны белү өчен.

- Ни өчен безгә вакытны белү кирәк соң?

- Вакытында мәктәпкә бару өчен... (Укучыларның җаваплары)

- Сәгать безгә вакытны дөрес бүләргә, көнебезне файдалы, матур үткәрергә ярдәм итә.

Димәк, без бүген дәрестә нәрсәләр турында сөйләшербез, нәрсәләр эшләрбез?(Вакыт,сәгать,режим турында)

Укучылар, бүгенге дәресебезнең темасы нинди булыр?(Көндәлек режим)
**2.**–Экрандагы яңа сүзләр белән танышу.(Балалар укытучы артыннан яңа сүзләрне кабатлыйлар.)Ә хәзер сүзлек дәфтәрләренә язып куябыз.
көндәлек режим –режим дня
сәгать-часы
иртә-утро
көн – день
кич -вечер
төн- ночь
**IV.Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**
**1**.Яңа сүзләр белән күнегү эшләү.(Укучыларга җөмләләр язылган карточкалар таратыла һәм укучы җөмләнең кайсы вакытка туры килүен әйтеп тактага беркетеп куя.)

*Кайсы вакытка туры килә?*

| ИРТӘ | КӨН | КИЧ |
|---|---|---|
| Мин мәктәпкә барам.<br>Мин юынам.<br>Мин тешне чистартам.<br>Мин зарядка ясыйм.<br>Мин иттәнге ашны ашыйм. | Мин мәктәптән кайтам.<br>Мин әнигә булышам .<br>Мин дәрес әзерлим.<br>Мин урамда уйныйм. | Мин телевизор карыйм.<br>Мин китап укыйм.<br>Мин йокларга ятам |

**2**.Физминут.
Без,без, без идек,
Без унике кыз идек.
Базга төштек май ашадык,
Келәткә кердек бал каптык,

Кап та коп, авызыңны ач та йом!
**3.**Интерактив тактада эшләү**.** Эш дәфтәре: 79нчы бит ,1нче күнегү.
Бирем:Өлгермешнең көн тәртибен төзергә.(Балалар такта янына чыгып дөрес тәртиптә номерларны куялар. )

**V.Рефлексив бәяләү**
1.Дәреснең темасы нинди булды?
2.Сез дәрес темасын аңладыгызмы?
3.Сезгә дәрес ошадымы?
**Өй эше :** - Үзеңнең көндәлек режимың турында сөйләргә.